Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Нырты авыл җирлеге Советы

# КАРАР

«15» июнь 2022 ел №15

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге Советның аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында**

Нырты авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

- «Нырты авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче (биләгән) затлар тарафыннан үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр бирү хакында» Нырты авыл җирлеге Советының 2013 елның 16 апрелендәге 9 номерлы карары;

- «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфа биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау хакында» Нырты авыл җирлеге Советының 2016 елның 18 апрелендәге 10 номерлы карары;

- «Нырты авыл җирлеге Советының 2016 елның 18 апрелендәге 10 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегендә муниципаль вазыйфа биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында»» Нырты авыл җирлеге Советының 2021 елның 9 июнендәге 14 номерлы карары.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы Т.А.Котдусов